| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

9 февраль 2022 ел Буа шәһәре № 9-24

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге 1-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге 1-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәгә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын хәтәрлек категориясенә кертү критерийлары өстәргә, 1 нче кушымта нигезендә;

1.2. Нигезләмәгә, 2 нче кушымта нигезендә, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу хәтәрлеге индикаторлары исемлеге өстәргә;

1.3. Нигезләмәгә муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләре һәм аның максатчан күрсәткечләре, шулай ук муниципаль торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр өстәргә, 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф.Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе Р. Р. Камартдинов